# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында” Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында” 2002 елның 15 октябрендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 10; 2003, № 9 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендә “якындагы сессиясендә” сүзләрен “якындагы утырышында” сүзләренә алмаштырырга;

2) 4 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Җәмәгатьчелек вәкиленең вәкаләтләре түбәндәге нигезләр буенча вакытыннан алда туктатыла:

1) җәмәгатьчелек вәкиленең вәкаләтләрен туктатуы турында язма гаризасы;

2) җәмәгатьчелек вәкиленең дәүләт яисә муниципаль хезмәткә керешүе, шулай ук аның дәүләт яисә муниципаль вазыйфа биләве;

3) җәмәгатьчелек вәкиленең адвокат статусын алуы;

4) җәмәгатьчелек вәкиленең нотариус итеп билгеләнеп куелуы;

5) җәмәгатьчелек вәкиленең оештыру-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә оешманың яисә учреждениенең җитәкчесе итеп билгеләнеп (сайланып) куелуы;

6) Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылу;

7) судның гаепләү карарының закон көченә керүе;

8) җәмәгатьчелек вәкиленең хокукый сәләте чикле булу турында йә аны хокукый сәләтсез дип тану турында суд карарының закон көченә керүе;

9) җәмәгатьчелек вәкилен хәбәрсез югалган дип тану йә закон көченә кергән суд карары нигезендә вафат булган дип игълан итү;

10) җәмәгатьчелек вәкиленең үлеме.";

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

"$1^1$. Үзенең яман атын чыгарырлык гамәлләр кылган, шулай ук җәмәгатьчелек вәкиле вазыйфаларын системалы рәвештә башкармаган очракта җәмәгатьчелек вәкиленең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылырга мөмкин.";

в) 2 өлештә "якындагы сессиядә" сүзләрен "Татарстан Республикасы Дәүләт Советының якындагы утырышында" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 11 апреле
№ 25-ТРЗ